КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 9 сентябрь г.Казань № 679

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлегенә (классификаторына) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлеген (классификаторын) раслау турында» 2018 ел,

24 декабрь, 1214 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 10 июль, 563 нче; 2019 ел, 16 июль, 586 нчы; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2019 ел, 27 декабрь, 1222 нче; 2020 ел, 10 июнь, 480 нче; 2020 ел, 31 август, 762 нче; 2020 ел, 16 декабрь, 1143 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1017 нче; 2022 ел, 24 гыйнвар, 44 нче; 2022 ел, 10 май, 426 нчы; 2022 ел, 15 июль, 677 нче; 2022 ел, 4 август, 757 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1202 нче; 2023 ел, 3 март, 201 нче; 2023 ел, 1 июнь, 669 нчы; 2023 ел, 3 июль, 773 нче; 2023 ел, 11 июль, 811 нче; 2023 ел, 5 сентябрь, 1076 нчы; 2023 ел, 28 сентябрь, 1193 нче; 2024 ел, 29 гыйнвар, 40 нчы; 2024 ел, 11 март, 131 нче; 2024 ел, 8 август, 633 нче; 2024 ел, 15 август, 662 нче; 2024 ел, 7 ноябрь, 967 нче; 2025 ел, 17 март, 152 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында (муниципаль хокукый актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда каралган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләре (муниципаль хезмәтләр) күрсәтүнең һәм эшләр башкаруның төбәк исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.24 пунктның 14 графасына түбәндәге эчтәлекле өстәмә юл өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | «әзерләнгән хисаплар саны (нәтиҗәләр һәм куллану өчен тәкъдимнәр белән), берәмлек»; | | | | |

5.1 пунктта:

18 графаның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Президентының «Федераль медицина-биология агентлыгы мәсьәләләре» 2024 елның 2 июлендәге 568 номерлы Указы белән расланган Федераль медицина-биология агентлыгы турында нигезләмә (6 пунктның 23 пунктчасы)»;

18 графаның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Суд-медицина экспертизасын үткәрү тәртибен раслау турында» 2023 елның 25 сентябрендәге 491н номерлы боерыгы белән расланган суд-медицина экспертизасын үткәрү тәртибе (2 пункт)»;

5.2 пунктның 18 графасындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Президентының «Федераль медицина-биология агентлыгы мәсьәләләре» 2024 елның 2 июлендәге 568 номерлы Указы белән расланган Федераль медицина-биология агентлыгы турында нигезләмә (6 пунктның 23 пунктчасы)»;

5.12 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

5.17 пунктның 2 графасында «үткәрү» сүзе алдына «чарасын» сүзен өстәргә;

7.6 пунктның 18 графасындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 17 августындагы б-2233 номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру стратегиясе»;

9.1 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

9.2 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

9.3 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

9.4 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

9.5 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

9.6 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

9.7 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

9.8 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

9.9 пунктның 7 графасында «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

11.16 пунктның 18 графасындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Юл хәрәкәтен оештыру буенча документации составы һәм эчтәлегенә карата таләпләрне билгеләү турында» 2025 елның 18 февралендәге 49 номерлы боерыгы»;

11.17 пунктның 18 графасындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Юл хәрәкәтен оештыру буенча документации составы һәм эчтәлегенә карата таләпләрне билгеләү турында» 2025 елның 18 февралендәге 49 номерлы боерыгы»;

12.9 пунктта:

7 графада «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

14 графада «кадастр кыйммәтен билгеләү барышында формалаштырылган хисаплар һәм документлар күчермәләре саны, берәмлек» сүзләрен «кергән мөрәҗәгатьләр саны, данә» сүзләренә алмаштырырга;

13.1 пунктның 13 графасында «урта эшмәкәрлек субъекты,» сүзләрен төшереп калдырырга;

14 бүлек үз көчен югалткан дип танырга;

17.99 пунктның 8 графасында «71.20.24» саннарын төшереп калдырырга;

21.6 пунктның 14 графасына түбәндәге эчтәлекле өстәмә юл өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | «әзерләнгән хисаплар саны, берәмлек»; | | | | |

21.7 пунктның 14 графасына түбәндәге эчтәлекле өстәмә юллар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | «әзерләнгән хисаплар саны, берәмлек | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | әзерләнгән хисаплар саны (нәтиҗәләр һәм куллану өчен тәкъдимнәр белән), берәмлек». | | | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин